ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 21 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Җир кодексына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 1999, № 8 (I өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 2 пунктчасына “саклау” сүзеннән соң “, җирләрне мелиорацияләү” сүзләрен өстәргә;

2) 4 статьяның 2 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

3) 12 статьяда:
а) 2 пунктта:
1 пунктчада “, шул исәптән дәвалау-савыктыру урыннарының һәм курортларның” сүзләрен төшереп калдырырга;
5 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“5) аеруча кыйммәткә ия җирләр.”;
б) 4 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;
в) 5 пунктта “, шулай ук дәвалау-савыктыру урыннарының һәм курортларның” сүзләрен төшереп калдырырга;
г) 6 пунктта беренче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “Дәүләт табигать тыюлыкларына, милли паркларга, табигать паркларына һәм табигать ядкарьләренә тискәре антропоген йогынтыларны булдырмый калу өчен алар янындагы җир кишәрлекләрендә һәм су объектларында саклау зоналары төзелә.”;

4) 15 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2. Запас җирләрдән файдалану аларны башка категориягә күчергәннән соң, запас җирләр аучылык җирләре чикләренә кертелгән очраклардан һәм федераль законнарда каралган башка очраклардан тыш, рөхсәт ителә.”;

5) 21 статьяның 2 пунктындагы беренче абзацында беренче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “Хезмәт буенча имана җирләре икътисадның аерым тармакларындагы оешмалар, шул исәптән транспорт, урман хуҗалыгы, урман сәнәгате, су, балык хуҗалыклары оешмалары, аучылык хуҗалыгы өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы оешмалар, дәүләт табигать тыюлыклары һәм милли парклар белән идарә итүче федераль дәүләт бюджет учреждениеләре хезмәткәрләренә түләүсез вакытлыча файдалануга бирелә.”;

6) 32 статьяның 2 пунктындагы 1 пунктчасында “крестьян (фермер) хуҗалыгы алып бару өчен” сүзләрен “крестьян (фермер) хуҗалыгы үз эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен” сүзләренә алмаштырырга;

7) 34 статьяда:

а) 1 пунктның 1 пунктчасында “крестьян (фермер) хуҗалыгы алып бару өчен” сүзләрен “крестьян (фермер) хуҗалыгы үз эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен” сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 пунктның 1 пунктчасында “крестьян (фермер) хуҗалыгы алып бару өчен” сүзләрен “крестьян (фермер) хуҗалыгы үз эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен” сүзләренә алмаштырырга;

8) 42 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

9) 48 статьяның 2 пунктындагы җиденче абзацын үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:

1) “Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында” 2007 елның 28 апрелендәге 18-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 16 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 4);

2) “Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында” 2009 елның 31 июлендәге 41-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 5 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 7 – 8 (III өлеш).

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты　　　　　　　　　　　　　　　　Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2014 елның 14 мае
№ 36-ТРЗ

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ